**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 1 августындагы 3216 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2020 елның 12 ноябрендәге 3266 номерлы**
**«Казан шәһәре территориясендә стационар булмаган**
**сәүдә объектларын урнаштыру**
**схемасын раслау турында»гы карарына**
**үзгәреш кертү хакында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.33, 39.36 статьялары, 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында»гы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 13 августындагы 553 номерлы «Муниципаль милектә булган җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында»гы карары (аңа Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 10 октябрендәге 732 номерлы, 2017 елның 18 сентябрендәге 675 номерлы, 2019 елның 17 июнендәге 498 номерлы, 2020 елның 29 декабрендәге 1221 номерлы, 2023 елның 13 гыйнварындагы 4 номерлы, 2023 елның 18 августындагы 985 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), Казан шәһәре Башкарма комитетының 2017 елның 25 апрелендәге 1417 номерлы «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында»гы карары нигезендә **карар бирәм:**

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2020 елның 12 ноябрендәге 3266 номерлы «Казан шәһәре территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын раслау турында»гы карары (аңа Казан шәһәре

Башкарма комитетының 2021 елның 5 июлендәге 1646 номерлы, 2021 елның 27 октябрендәге 2791 номерлы, 2022 елның 3 мартындагы 648 номерлы, 2022 елның 1 апрелендәге 914 номерлы, 2023 елның 2 февралендәге 279 номерлы, 2023 елның 10 ноябрендәге 3429 номерлы, 2024 елның 29 мартындагы 1191 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) кушымтасына, түбәндәге эчтәлекле юл өстәп, үзгәреш кертергә:

| **Реестр номеры** | **Факт буенча адресы** | **Факт буенча профиле** | **Мәйданы, кв.м** |
|---|---|---|---|
| «В-78 | Подлужная урамы,<br>6 номерлы йорт янында | Җәмәгать туклануы | 85 дән артык түгел» |

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**